# 2013–2014 нче елгы эш планының үтәлешенә анализ.

1.Балалар бакчасы турында белешмә.

1.1. Татарстан Республикасы Аксубай  муниципаль районының Иске Ибрай авылы  муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.
Адрес:
Аксубай районы , Иске Ибрай авылы,Мәдәният  урамы, 2а. Телефон: 2-65-04.
Гамәлгә куючы:Аксубай  муниципаль районының башкарма комитеты.
Мөдир:Хаснова Миләүшә Мисалиховна
Балалар бакчасына лицензия бирелде: 2011 нче елда,срогы чикләнмәгән.
1.2. Балалар бакчасы үзенең эшчәнлеген түбәндә
күрсәтелгән документлар нигезендә алып бара:
Устав, гамәлгә куючы белән килешү, локаль документлар (Эчке тәртип кагыйдәләре, Хезмәт вазыйфасы инструкцияләре (Должностные инструкции), Ата-аналар белән килешү һ.б.).
1.3. 2013 –2014 нче уку елында 2 төркем эшләде, 40 бала тәрбияләнде

| Төркемнәр | Бала саны | Гендер аерма | | Милли состав |
|---|---|---|---|---|
| | | кыз | малай | |
| кечкенәләр | 16 | 9 | 7 | татар |
| зурлар | 26 | 15 | 11 | татар |
| барлыгы | 42 | 24 | 18 | татар |

1.4. Балалар бакчасында белем-тәрбия бирү эшчәнлеге түбәндә күрсәтелгән программалар, технологияләр буенча алып барылды.
1.Программа дошкольного образования “От рождения до школы”Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева;
2.Программа воспитания и обучения в детском саду. М.А.Васильева, В.В.Гербова, Т.С.Комарова
3.Региональная программа дошкольного образования. Р.К.Шаехова.
4.Программа по обучению русскому языкуР.А.Бурганова
5.Балалар бакчаларында сөйләм теле үстерү программасы
6.М.Ф.КашаповаГаиләдә, балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасыК.В.Закирова, Р.А.Низамов
7.Основы безопасности для детей дошкольного возрастаР.Б. Стеркина, О.Л. Князева
8.Туган як табигате белән таныштыру Р.А.Борһанова

1.5. Балалар бакчасының материаль-техник базасына характеристика
2013 –2014 нче уку елы дәвамында балалар бакчасының материаль-техник базасын ныгыту буенча планлы эш алып барылды. Тәрбия-белем бирү процессын нәтиҗәле итеп оештыру өчен яңа укыту-методик комплекты (УМК) буенча методик әсбаплар, күрсәтмә материаллар, экран, проектор алынды. Музыкаль бәйрәмнәр үткәрү өчен яңа атрибутлар булдырылды. Балалар бакчасының бинасы канәгатьләнерлек хәлдә, җылылык, су белән тәэмин ителгән. Территорияне яшелләндерү буенча даими эш башкарыла: газоннар чәчелде, чәчәкләр, яшелчәләр утыртылды.
Мәктәпкә әзерлек һәм уртанчылар төркемнәрендә күләмле ремонт эшләре башкарылды. Зурлар төркеменең йокы, уен, прихожая бүлмәләрендә түшәм, стеналар ремонтланды, буялды. Кечкенәләр төркеменең тәрәзә-ишекләре, шкафлары өлешчә ремонтланды.
Барлык төркемнәрдәге яктырткычлар энергия саклый торганнары белән алыштырылды.Тәрбиячеләргә 1 компьютер,проектор алынды.
Стендлар яңартылды, төркем почмакларына информация урнаштыру өчен кесәчекләр ясатылды.
2.Балаларның физик үсешенә анализ.
Коллективның көндәлек бурычы –балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау, авыру очракларын киметү. Балаларның хәрәкәт активлыгы физкультура шөгыльләре, иртәнге гимнастика, прогулкалар аша тормышка ашырыла. Ел дәвамында бала организмын ныгытуны оптималь итеп оештыруга игътибар ителде. Тәрбиячеләр балаларның сәламәтлеген даими күзәтү астында тота,прививкаларны планлаштыру,витаминнар бирү системага салынган, санитария–гигиена таләпләренең үтәлеше контрольгә алынган. Балаларның тормышын, сәламәтлеген саклау, нерв системасын ныгыту, бала организмын чыныктыруга зур игътибар бирелде. Тәрбиячеләр шәфкать туташы белән берлектә һава һәм су процедуралары, иртәнге гимнастика выкытында, инфекция чорында сарымсак, суган, оксолин мае кайнаган тозлы су белән тамак чайкау, төймәле юлдан, кабыргалы юллардан йөрү, төзтабанлылыкны кисәтү чараларын системалы рәвештә алып бардылар.Физкультура шөгыльләре тиешле югарылыкта үткәрелә, тәрбиячеләр, физкультура тәрбиячесе Мотыгуллина К.М.,Мусина Г.В. белән берлектә һәр төркемдә шөгыльләрне балаларның яшь үзенчәлеген, сәламәтлеген исәпкә алып оештыралар. Эшләде.“ФГТ һәм ФГОС таләпләрен тормышка ашыру буенча “мәктәп һәм балалар бакчалар арасында хезмәттәшлек “ -темасына КМО үткәрелде.КМО да Мотыгуллина ,Сулейманова Р.В.ачык шөгыльләр күрсәттеләр һәм үзләренең эш тәҗрибәсе белән уртаклаштылар.Белем һәм физик культура шөгыльләрен үткәрүдә интеграцион эшчәнлекне оештыру спорт-сәламәтләндерү эшчәнлегенә әти-әниләрне дә активлаштыру отышлы булуы ачыкланды. Әти-әниләр

катнашында һәр төркемдә спорт бәйрәмнәре: “Ягез әле, әтиләр”, район күләмендә үткәрелгән балалар Спартакиадасы, “Кышны озату” спорт бәйрәмнәре бик күңелле үтте.Балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү буенча һәр балага сәламәтлек мониторингы алып бару, балаларның физик үсешен даими контрольдә тоту, балаларны сәламәтлек төркемнәренә бүләргә мөмкинлек бирә

| **Сәламәтлек төркеме** | 2011-2012 | 2012-2013 | 2013-2014 |
|---|---|---|---|
| 1 нче сәлам төрк | 1 | 13 | 1 |
| 2 нче сәлам төрк. | 2 | 22 | 1 |
| **3 нче сәлам төрк.** | **2** | **2** | **2** |
| **4 нче сәлам төрк.** | **-** | **-** | **-** |

2.Педагогик кадрлар Балалар бакчасының штат расписаниесе учреждениенең төренә һәм статусына туры китереп бирелә.Иске Ибрай авылы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе тулысынча педагогик һәм техник

| № | | **2013-2014 уку елына** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **барлыгы** | **кечкенәләр** | **зурлар** |
| 1 | Балалар саны | 40 | 15 | 28 |
| 2 | Авыру көннәре | 365 | 186 | 179 |
| 3 | Бер баланың авыру көннәре | 17 | 11 | 6 |
| 4 | Бер авыру көннәре | 16 | 11 | 5 |
| 5 | Авыру ничә тап. булган | 52 | 16 | 36 |
| 6 | Бер балага ничә көн | 1,2 | 1.0 | 1,3 |
| 7 | Еш авыручы | 4 | 3 | 1 |
| 8 | Йөреш | 6121 | 1894 | 4227 |

персонал белән тәэмин ителгән

| Хезмәт вазифасы | Саны |
|---|---|
| Мөдир | 1 |
| Тәрбиячеләр | 3 |
| Музыкаль җитәкче | 1 |
| Кече тәрбиячеләр | 3 |

Барлык педагоглар да педагогик белемгә ия, шуларның 2 се югары белемле, калганнары махсус урта белемле




Педагогларның    аттестация үтү дәрәҗәсе




2013-2014 нче  уку  елында   Мотыгуллина К.М.  беренче квалификацион категориягә  аттестацияләнде.

2013-2014 нче уку елында балалар бакчасын 8 бала тәмамлады. Алар Иске ибрай урта урта мәктәбенә укырга керделәр

2013-2014 нче уку елында еллык планның нәтиҗәлелегенә һәм үтәлешенә анализ.

Балалар бакчасы уку елында түбәндәге бурычларны алга куеп эшләде:
1.Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны аралашу һәм телләргә өйрәтүдә яңа алымнарны гамәлгә ашыру. УМК –укыту-методик комплектны куллану.
2.Балаларга сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗ тәрбияләү, яңа технологияләр, алдынгы тәҗрибәләр өйрәнеп эшләү.

3.Федераль дәүләт таләпләренә нигезләнеп, балалар бакчасының эшчәнлеген яңача планлаштыру һәм оештыру системасына күчү.
4.Балаларны хезмәткә өйрәтү, аларның сәләтен ачарга ярдәм итү, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.
Еллык бурычларның берсе аралашу һәм телләргә өйрәтүдә яңа алымнарны гамәлгә ашыру иде, бу бурычны үтәү өчен түбәндәге чаралар оештырылды.
1. Педагогик киңәшмә: "Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны аралашу һәм телләргә өйрәтүдә яңа алымны гамәлгә ашыру".
2. Ачык шөгыльләр: укыту-методик комплектларын кулланып, тәрбияче Мотыгуллина  К.М.рус теле буенча шөгыль үткәрде.
Нугуманова К.В. зурлар төркеме балалары белән "Шалкан" әкиятен сәхнәләштерде.
3. Балаларның рус телен үзләштерү эшчәнлеге буенча тематик контроль.
4. Әти-әниләр өчен анкета: "Балаларны рус теленә өйрәтү".
Уздырылган мониторингка караганда, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме балалары сөйләмендә позитив үзгәрешләр күренә. Ел башы нәтиҗәләре белән чагыштырганда, уку елы ахырында рус телен үзләштерү –уртанчылар төркемендә 78% , –зурлар-мәктәпкә әзерлек төркемендә –85 % тәшкил итә.
Шулай ук балалар бакчасында хезмәт тәрбиясе бирү буенча эш алып барылды. Бу бурычны чишәр өчен түбәндәге чаралар оештырылды.
1. Педагогик киңәшмә. "Балаларга хезмәт тәрбиясе бирү –төп бурычларның берсе".
2. Тематик тикшерү "Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда хезмәт күнекмәләре формалаштыру". Хезмәт тәрбиясе буенча эш системалы рәвештә иртәнге, кичке  чорларда, прогулкада планлаштырылган. Балалар ашханәдә, табигать почмагында график буенча кизү торалар. Тәрбиячеләр балалар белән нинди индивидуаль эшкә, балаларның мөстәкыйль эшчәнлегенә, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен бирүгә зур әһәмият бирәләр.
3. Хезмәт тәрбиясе атналыгы кысаларында тәрбияче Мусина Г.В.. балаларга хезмәт тәрбиясе бирү  буенча ачык шөгыльләр күрсәтте, педагогик киңәшмәдә шушы тема буенча чыгышлар ясап үзләренең фикерләре белән уртаклашты."ФГТ һәм ФГОС кысаларында балалар бакчалары һәм мәктәп арасында хезмәттәшлек" темасы буенча КМО  уздырылды. КМО нәтиҗәле үтте.
Балалар бакчасында әти-әниләр белән уздырылган чаралар гомумән күп булды: спорт бәйрәмнәре, төрле бәйгеләр, консультацияләр, ярминкәләр, бәйрәм иртәләре һәм кичәләре, концерт һ.б. Әти-әниләр белән бердәм булып эшләү, аларны төрле чараларда катнаштыру, тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеген тагын да нәтиҗәлерәк итеп оештырырга мөмкинлек тудыра.Бу уку елында тәрбияче Мотыгуллина К.М. беренче категориягә аттестация үтте.2014 елда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 128 яшь тулу уңаеннан балалар бакчасында чаралар уздыру планы төзелде. Балаларда һәм әти-әниләрдә Г.Тукайның иҗатына карата кызыксыну уяту, үз халкың белән горурлану хисе тәрбияләү максатыннан балалар һәм әти-әниләр өчен

Г.Тукайның иҗатына карата  рәсем, кул эшләре буенча бәйге уздырылды.Әти-әниләр актив катнашып,үзләренең иҗадилыкларын күрсәтә белделәр.
“Ел тәрбиячесе” конкурсында катнашып, музыкаль җитәкче Сулейманова Р.В. мактау грамотасына лаек булды.
Балалар бакчасының эшчәнлегенең нәтиҗәләре педагогларның теләк омтылышлары, тырышлыгы, уңганлыгы белән генә түгел, ә бәлки куелган максатларың ничек гамәлгә ашырылуы, балаларның нинди уңышларга ирешүе, нинди белемнәргә ия булуы белән билгеләнә. Педколлектив бу уңышларга укыту-тәрбия эшендә яңа үтемле  алымнар,белем эчтәлеген баету, белем дәрәҗәсен күтәрү нәтиҗәсендә иреште.
Бурычлар:
1.Балаларда сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗ тәрбияләүдә традицион булмаган җиһазлар куллану
2. ФДТ тормышка ашыру буенча заманча технологияләрне кулланып, үстерелешле тирәлекне баету
3.Эксперимент-тикшерү эшчәнлеге аша балаларның танып белү һәм интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү
4.Укыту-методик комплектны кулланып, балаларга төп дәүләт телләрен өйрәтү (ана теле, рус теле)